# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 15.11.2023

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат – Асты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елнын 15 ноябрендә узган гражданнар жыенынын" «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Нарат – Асты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, моннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт узучы, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә жибәру очен узарасалым кертергә килешэсезме:

1) Нарат-Асты торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (2 данә-кран , тоташтыру өчен торбалар сатып алу)

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 32 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 23 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 23 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенен Нарат- Асты авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен – дорес дип таныргa.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Нарат – Асты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән вакытлы хәрби хезмәт узучы, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2024 елда үзара салым кертергә риза:

1) Нарат-Асты торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (2 данә-кран , тоташтыру өчен торбалар сатып алу)

3. Җыен нәтижэлэрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы ________ И.Х.Хадиуллин